ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО БИОЛОГИЧЕСКИМ РЕСУРСАМ
ул. Карима Тинчурина, д. 29, г. Казань, 420021

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИОЛОГИК РЕСУРСЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ
К. Тинчурин ур., 29 йорт, Казан шәһәре, 420021

Телефон: (843)211-66-94, факс: (843)211-66-47, E-Mail:ojm@tatar.ru, сайт:http://ojm.tatarstan.ru

Приказ Казан шәһәре Боерык

28.02.2023 № 76 - од

«Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында әлеге вазыйфаларны биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында хисаплар (кертемнәр) ачу һәм булу, акча һәм кыйммәтләрне саклау, чит ил финансына ия булу һәм (яисә) файдалану тыела торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2019 елның 22 августындагы 246-од номерлы Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты боерыгына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының норматив хокукый актларын «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән тәңгәлләштерү максатларында

боерам:

1. «Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында әлеге вазыйфаларны биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында хисаплар (кертемнәр) ачу һәм булу, акча һәм кыйммәтләрне саклау, чит ил финансына ия булу һәм (яисә) файдалану тыела торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында»

2019 елның 22 августындагы 246-од номерлы Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта тиешле килештәге «Президент» сүзен тиешле килештәге «Рәис» сүзенә алыштырырга.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

3. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Рәис Ф.С. Батков